КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 июль г.Казань № 674

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 ноябрь, 1048 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 33 нче; 2020 ел, 26 февраль, 147 нче; 2020 ел, 27 июль, 626 нчы; 2020 ел, 9 ноябрь, 1002 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1078 нче; 2021 ел, 3 февраль, 52 нче; 2021 ел, 23 апрель, 279 нчы; 2021 ел, 25 сентябрь, 916 нчы; 2022 ел, 17 февраль, 135 нче; 2022 ел, 30 май, 495 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программа бурычлары» юлының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак фондының сыйфатын яхшырту;»;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлының 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Күпфатирлы йортларның техник торышын яхшырту;»;

Программаның 2 бүлегендә:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак фондының сыйфатын яхшырту;»;

алтмыш беренче – алтмыш дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортларның техник торышын яхшырту» ярдәмче программасы (алга таба – 5 нче ярдәмче программа).

5 нче ярдәмче программаның төп максаты – торак фондының сыйфатын яхшырту.

5 нче ярдәмче программаның бурычы – күпфатирлы йортларда ремонт ясауны нәтиҗәле планлаштыру һәм үз вакытында үткәрүне оештыру, озакка җитә торган материалларны кулланып, ремонт ясаганда нәтиҗәле техник чишелешләрдән һәм комплекслылыктан файдалану.

5 нче ярдәмче программа кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасында каралган чаралар, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планына кертелгән күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәргәндә эшләрнең аерым төрләрен башкару чаралары гамәлгә ашырылачак.»;

Программаның кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасы чараларын гамәлгә ашыру» ярдәмче программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин